| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

07.08.2025 № 875

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының муниципаль милкенә күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында карар кабул итү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 79 статьясы, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы муниципаль милек объектларына капитал салулар рәвешендә бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыру тәртибен раслау һәм күрсәтелгән объектларга бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында карарлар кабул итү турында» 2025 елның 17 июнендәге 641 номерлы карары нигезендә, муниципаль мөлкәт бәясен арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карарга 1нче кушымта нигезендә «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең күчемсез мөлкәт объектларын муниципаль милеккә сатып алу рәвешендә бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында карар кабул итәргә.

2. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкенә сатып алына торган күчемсез мөлкәт объектлары исемлеген әлеге карарга 2нче кушымта нигезендә раслырга.

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетын күчемсез милек объектларын сатып алу буенча заказчы итеп билгеләргә.

4. Заказчыга «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» 2013 елның 05 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә муниципаль контракт төзүне тәэмин итәргә һәм бюджет акчаларыннан максатчан файдалануны тикшереп торуны гамәлгә ашырырга.

5. Бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны 2025 елга расланган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе җаваплылыгында калдырырга.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 7 августындагы 875 номерлы карарына 1нче кушымта

**Решение**
**«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкенә күчемсез мөлкәт объектларын сатып алуга бюджет инвестицияләрен әзерләү һәм гамәлгә ашыру турында**

**1.**Инвестицияләү **юнәлеш**е - күчемсез мөлкәт объектын сатып алу.

**2. Күчемсез милек объекты исеме - бинасы** ("Җылылык казаннарын ремонтлау цехы**").**

**3.Күчемсез милек объектының урнашу ур**ыны - Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Нурлат шәһәре, Совет урамы, 130 йорт.

**4.Күчемсез милек объектын характерлаучы параметрлар** - кадастр номеры 16:56:0136:326, мәйданы 628,8 кв.м., 3 кат, билгеләнеше - җитештерү билгеләнешендәге объект, файдалануга тапшыру - 2001 ел.

**5.Бюджет чараларын баш бүлүче һәм муниципаль заказчы** исеме - «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлеге исеменнән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты.

**6. Күчемсез милек объектын сатып алу срогы - 2025** ел

**7. Күчемсез милек объектын сатып алу бәясе - 18 702 405**,00 сум.

**8. Бюджет инвестицияләренең гомуми (чикле) күләме (мең сум) -** 18 702 405,00 сум.

**9. Бюджет инвестицияләренең гомуми (өстәмә) күләмен гамәлгә ашыру еллары буенча бүленеш (мең сум) - 2025** ел - 18 702 405,00 сум.

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 7 августындагы 875 номерлы карарына 2нче кушымта

.

**«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең муниципаль милкенә сатып алына торган күчемсез мөлкәт объектлары**

| т/б № | Күчемсез милек объекты исеме | Инвестицияләү юнәлеше | ГРБС һәм муниципаль заказчы исеме | Объектның мәйданы ($м^2$) | Объектның урнашу урыны (адресы) | Җир кишәрлегенең кадастр номеры | Гамәлгә кертү срогы | Сатып алына торган мөлкәтнең бәясе (мең сумнарда) | Финанслау чыганаклары (мең сумнарда) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | Барлыгы | Республика бюджет | Җирле бюджет |
| 1 | Бина ("Җылылык казаннарын ремонтлау цехы") | Торак булмаган күчемсез милек сатып алу | «Нурлат муниципаль районы» муниципаль берәмлеге исеменнән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Башкарма комитеты | 628,8 | Татарстан Республикасы, Нурлат районы, Нурлат ш., Совет ур., 130 йорт | 16:56:010136:326 | 2001 | 18 702 405,00 | 18 702 405,00 | 0 | 18 702 405,00 |
| | Барлыгы: | | | | | | | 18 702 405,00 | 18 702 405,00 | 0 | 18 702 405,00 |